СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
«09» август 2023 г.

Карар
№3-28

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-КҮЛавыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 июнендәге 2-20 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 89 статьясының 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Башлык,

Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге
Советы рәисе /И.Н.Сәләхетдинов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының
09.08.2023 ел, №3-28
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр

1. 19 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«« Авыл торак пунктының Старостосы составына әлеге торак пункт кергән җирлек Советы тарафыннан авыл торак пунктындагы гражданнар җыены тәкъдиме буенча билгеләнә. Авыл торак пунктының Старостасы итеп әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары, йә тәкъдим ителгән көнгә 18 яшькә җиткән һәм шушы авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

2. 19 статьяның 3 өлешендә «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;»;

3. 19 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;»;

4. 31 статьяның 11 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5. 31 статьяның 12 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6. 31 статьяның 13 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

7. 41 статьяның 5 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;»;